КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 март г.Казань № 275

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) һәм https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, сайлап алуны үткәрү сроклары башланган көнгә кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, заявкаларны сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (сайлап алуны үткәрү турында белдерү) урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы затларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртип нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче дип танылган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куярга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

5 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан заявка бирелә торган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

7 пунктта:

өченче абзацта «400,0» саннарын «600,0» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «200,0» саннарын «300,0» саннарына алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турындагы,

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан агымдагы елдан иртәрәк булмаган вакытта Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта, аны Идарә яки авыл яки шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга рөхсәт бирелгән төрдәге җир кишәрлеге аренда хокукында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданныкы булса, җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе;

Татарстан Республикасы муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелгән мини-ферма төзүнең җыелма һәм локаль смета исәп-хисаплары;

сайлап алуда катнашуга заявка бирелгән датага кадәр төзелеш төгәлләнү шарты белән башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар (КС-2 номерлы унификацияләнгән форма);

сайлап алуда катнашуга заявка бирелгән датага кадәр төзелеш төгәлләнү шарты белән башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә кәгазьләре (КС-3 номерлы унификацияләнгән форма);

Татарстан Республикасы муниципаль районы башкарма комитетының шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мини-ферма төзелешен алып баруны тикшерү комиссиясен (алга таба – район комиссиясе) төзү турындагы карары;

район комиссиясенең шәхси ярдәмче хуҗалыкта сыерларны асрау буенча ветеринария кагыйдәләре үтәлеше һәм мини-ферма төзелешенең фактгагы торышы турында күчмә тикшерү беркетмәсе;

төзелгән яки кимендә 50 проценты әзер булу стадиясендә булган мини-ферманың булуы һәм фактгагы торышы турында район комиссиясе тарафыннан расланган акт;

җир кишәрлегенең мини-ферма төзелгәнгә кадәр һәм төзелгәннән соң җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез объектларның урнашу урыны күрсәтелгән, район комиссиясе тарафыннан расланган шәһәр төзелеше планы;

сөт бирү юнәлешендәге мини-ферманың тышкы һәм эчке яктан төшерелгән, башкарма комитет тарафыннан расланган фотосурәтләре.

Сервиста автомат режимда алына торган мәгълүматлар һәм документлар:

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының паспорт мәгълүматлары (гомуми мәгълүматлар һәм яшәү урыны бүлекләре);

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча электрон хуҗалык кенәгәсеннән агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыкта сыерларның баш саны булуын раслый торган өземтә;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

заявкаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта заявканы кире алырга;

кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта заявканы кабат бирергә, шул ук вакытта заявка кергән көндә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Сервиста шәхси кабинетны мөстәкыйль ачу һәм (яки) заявка булдыру өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан Идарәгә яки башкарма комитетка файдалану мөмкинлеге булган шәхси кабинет аша шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан исеменнән заявка бирү өчен Идарәгә яки башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Моның өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинга бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә яки башкарма комитетка тапшырырга һәм түбәндәге документларны күрсәтергә кирәк:

паспорт;

салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ.»;

9 пунктның 9.1 пунктчасында:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.5 пунктның өченче абзацында «Идарәләр тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисаплар җыелма белешмә кәгазьләрен кертү» сүзләрен «субсидия бирү турында карар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның сигезенче абзацында татар текстында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе күрсәткеченә» сүзләренә алмаштырырга.

13 пунктта:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә» һәм «мәҗбүри» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгалләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сату өчен билгеләнгән һәм нәселле булган кысыр таналар һәм тана сыерлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) һәм https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, сайлап алуны үткәрү сроклары башланган көнгә кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, заявкаларны сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (сайлап алуны үткәрү турында белдерү) урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы затларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртип нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче дип танылган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куярга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»:

5 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан заявка бирелә торган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

7 пунктта:

бишенче абзацта «30,0» саннарын «60,0» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта «40,0» саннарын «70,0» саннарына алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турындагы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан агымдагы елдан иртәрәк булмаган вакытта Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта, аны Идарә яки авыл яки шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга рөхсәт бирелгән төрдәге җир кишәрлеге аренда хокукында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданныкы булса, җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе;

агымдагы финанс елында юридик зат статусына ия һәм әлеге продукцияне турыдан-туры җитештерүчеләре булган авыл хуҗалыгы оешмаларыннан сату өчен билгеләнгән кысыр таналар һәм (яки) тана сыерлар сатып алу чыгымнарын раслый торган документлар (сатып алу-сату шартнамәләре, товар-транспорт накладнойлары, түләүче банк тарафыннан расланган түләү документлары, исемен, сатып алына торган кысыр таналарның яшен (21 айдан (әмма 26 айдан өлкәнрәк булмаган), тере авырлыгы кимендә 430 килограмм) һәм (яки) тана сыерларның яшен (27 айдан (әмма 36 айдан өлкәнрәк булмаган), тере авырлыгы кимендә 450 килограмм) күрсәтеп, авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алуга кабул итү-тапшыру актларының төп нөсхәләре һәм күчермәләре);

агымдагы финанс елында нәселле терлекнең дәүләт регистрында теркәлү турында таныклыгы булган нәселле терлек заводыннан һәм нәселле терлек репродукторларыннан нәселле кысыр таналар һәм (яки) тана сыерлар сатып алу чыгымнарын раслый торган документлар (сатып алу-сату шартнамәләре, товар-транспорт накладнойлары, түләүче банк тарафыннан расланган түләү документлары, исемен, сатып алына торган кысыр таналарның яшен (21 айдан (әмма 26 айдан өлкәнрәк булмаган), тере авырлыгы кимендә 430 килограмм) һәм (яки) тана сыерларның яшен (27 айдан (әмма 36 айдан өлкәнрәк булмаган), тере авырлыгы кимендә 450 килограмм) күрсәтеп, авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алуга кабул итү-тапшыру актларының төп нөсхәләре һәм күчермәләре);

ветеринария белешмә кәгазе һәм (яки) сатып алына торган, сату өчен билгеләнгән һәм (яки) нәселле булган кысыр таналарга һәм (яки) тана сыерларга терлек сатып алган көндә рәсмиләштерелгән таныклык;

нәселле терлекнең дәүләт регистрында нәселле терлекне сатучы оешма теркәлү турында таныклык;

сатып алына торган нәселле кысыр таналарга һәм (яки) тана сыерларга нәсел таныклыгы.

Сату өчен билгеләнгән һәм (яки) нәселле булган кысыр таналарның һәм (яки) тана сыерларның бер башына 10,0 мең сум күләмендә субсидия алу өчен түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен өстәмә рәвештә теркәргә кирәк:

район яки шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең дәүләт бюджет учреждениесеннән агымдагы елда шәхси ярдәмче хуҗалыкта лейкоз белән авырган һәм (яки) лейкоз вирусын йоктырган сыер булуын раслый торган белешмә кәгазе (үткәрелгән экспертиза күчермәсен теркәп);

лейкоз белән авырган һәм (яки) лейкоз вирусын йоктырган сыерны алып чыгып китү турында Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының дәүләт ветеринария берләшмәсе тарафыннан расланган ветеринария иярчен документлары;

сәүдә арадашчылары катнашуыннан башка, терлек чалу пунктының (ит комбинатының) лейкоз белән авырган һәм (яки) лейкоз вирусын йоктырган сыерны кабул итүен раслый торган документ (шартнамә һәм кабул итү-тапшыру акты, товар накладное).

Сервиста автомат режимда алына торган мәгълүматлар һәм документлар:

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының паспорт мәгълүматлары (гомуми мәгълүматлар һәм яшәү урыны бүлекләре);

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның электрон хуҗалык кенәгәсеннән сатып алынган терлекне исәпкә кую фактын раслый торган өземтә;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

заявкаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта заявканы кире алырга;

кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта заявканы кабат бирергә, шул ук вакытта заявка кергән көндә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

түбәндәге эчтәлекле 8[1] пункт өстәргә:

«8[1]. Сервиста шәхси кабинетны мөстәкыйль ачу һәм (яки) заявка булдыру өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданин Идарәгә яки башкарма комитетка файдалану мөмкинлеге булган шәхси кабинет аша шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан исеменнән заявка бирү өчен Идарәгә яки башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Моның өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинга бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә яки башкарма комитетка тапшырырга һәм түбәндәге документларны күрсәтергә кирәк:

паспорт;

салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ.»;

9 пунктта:

9.1 пунктчада:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.5 пунктның өченче абзацында «Идарәләр тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисаплар җыелма белешмә кәгазьләрен кертү» сүзләрен «субсидия бирү турында карар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә» һәм «мәҗбүри» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән өлкәнрәк бияләр асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) һәм https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, сайлап алуны үткәрү сроклары башланган көнгә кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, заявкаларны сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (сайлап алуны үткәрү турында белдерү) урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы затларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртип нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче дип танылган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куярга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

5 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип таныйрга;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан заявка бирелә торган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган

инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турындагы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан агымдагы елдан иртәрәк булмаган вакытта Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта, аны Идарә яки авыл яки шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга рөхсәт бирелгән төрдәге җир кишәрлеге аренда хокукында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданныкы булса, җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе;

агымдагы елда өч яшьтән өлкәнрәк бияләргә йогышлы һәм аеруча куркыныч авыруларга каршы вакцинация уздыруны раслый торган, район яки шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре тарафыннан расланган акт.

Сервиста автомат режимда алына торган мәгълүматлар һәм документлар:

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының паспорт мәгълүматлары (гомуми мәгълүматлар һәм яшәү урыны бүлекләре);

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның электрон хуҗалык кенәгәсеннән агымдагы финанс елының 1 гыйнварына бияләр саны булуы фактын раслый торган өземтә;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

заявкаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта заявканы кире алырга;

кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта заявканы кабат бирергә, шул ук вакытта заявка кергән көндә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Сервиста шәхси кабинетны мөстәкыйль ачу һәм (яки) заявка булдыру өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан Идарәгә яки башкарма комитетка файдалану мөмкинлеге булган шәхси кабинет аша шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан исеменнән заявка бирү өчен Идарәгә яки башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Моның өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинга бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә яки башкарма комитетка тапшырырга һәм түбәндәге документларны күрсәтергә кирәк:

паспорт;

салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ.»;

9 пунктта:

9.1 пунктчада:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктның өченче абзацында «Идарәләр тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисаплар җыелма белешмә кәгазьләрен кертү» сүзләрен «субсидия бирү турында карар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә» һәм «мәҗбүри» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләрен асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) һәм https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, сайлап алуны үткәрү сроклары башланганга кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, заявкаларны сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (сайлап алуны үткәрү турында белдерү) урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы затларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртип нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче дип танылган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куярга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

5 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан заявка бирелә торган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры

килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турындагы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан агымдагы елдан иртәрәк булмаган вакытта Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта, аны Идарә яки авыл яки шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга рөхсәт бирелгән төрдәге җир кишәрлеге аренда хокукында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданныкы булса, җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе;

агымдагы финанс елында савым сыерларына карата үткәрелә торган язгы һәм көзге ветеринария-профилактика чараларына тулысынча түләүне раслый торган түләүле ветеринария хезмәтләре күрсәтүгә шартнамә.

Сервиста автомат режимда алына торган мәгълүматлар һәм документлар:

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының паспорт мәгълүматлары (гомуми мәгълүматлар һәм яшәү урыны бүлекләре);

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның электрон хуҗалык кенәгәсеннән агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата бер яшьтән зуррак булган савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләре булу фактын раслый торган өземтә;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

заявкаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта заявканы кире алырга;

кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта заявканы кабат бирергә, шул ук вакытта заявка кергән көндә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Сервиста шәхси кабинетны мөстәкыйль ачу һәм (яки) заявка булдыру өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан Идарәгә яки башкарма комитетка файдалану мөмкинлеге булган шәхси кабинет аша шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан исеменнән заявка бирү өчен Идарәгә яки башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Моның өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинга бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә яки башкарма комитетка тапшырырга һәм түбәндәге документларны күрсәтергә кирәк:

паспорт;

салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ.»;

9.1 пунктчада:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктның өченче абзацында «Идарәләр тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисаплар җыелма белешмә кәгазьләрен кертү» сүзләрен «субсидия бирү турында карар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә» һәм «мәҗбүри» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.».

2. Бу карар (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның илле җиденче, йөз унбишенче, йөз алтмыш өченче, ике йөз тугызынчы абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин